Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының егерме өченче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

7 июль, 2022 ел № 164

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, 2022 елның 27 июнендәге гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегенең генераль планын электрон чыганактагы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегенең генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә (https://fgistp.economy.gov.ru/).

3. Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2017 елның 7 ноябрендәге 24 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирле үзидарә органнары белән үзара

хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов